**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 31 » 07 2018 № 406

Аксубаево

Җирле үзидарә органнары тарафыннан
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2013 елның 04 апрелендәге 111 номерлы карарына ярашлы рәвештә, түбәндәге
**КАРАР БИРӘМ**:

1. Расларга:

1.1. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1-нче кушымта).

1.2. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. васыятьләр таныклыгы буенча һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә http:/ Aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында.

3. «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 04 маендагы 226 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Муратшинга йөкләргә.

Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Ф. Горбунов